| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.01.2024 Олы Кайбыч ав. № 8

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 апрелендәге 190 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МБУ җитәкчеләренең һәм белгечләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 22 апрелендәге 190 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (2022 елның 07 февралендәге 57 номерлы үзгәрешләр белән):

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|

| белгечләр вазыйфалары | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 27 700 |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 25 500 |
| Бүлек башлыгы | 21 700 |
| Әйдәп баручы хисапчы | 19 300 |
| хисапчы | 18 000 |

Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия штат расписаниесенә җитәкче урынбасары вазыйфасын кертү шарты булып, структурада һәрберсендә кимендә 5 берәмлек штат саны булган кимендә 3 бүлек булу тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләрендә штат саны кимендә 5 берәмлек булырга тиеш.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы,
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесенең
Беренче урынбасары Э.Х.Заһидуллина